Кадырова, З. "Төп геройның алга таба яшисе бар..." / З. Кадырова; [әңгәмәдәш] Р. Рахматуллина // Ирек мәйданы. – 2025. – №28 (17 июль). – Б 4-5.





Халык китап укымый, дибез. Ә язучы Зифа Кадырова китапларын ким дигәндә 10 мең тираж белән бастыра. Апрель азагында Зифа апаның "Язмышыңа язылганны..." исемле чираттагы китабы дөнья күрде. Шулай ук 10 мең тираж белән чыккан. Бу китабын да кибетләргә куя тора, бетә бара икән.

"Язмышыңа язылганны..." дип аталган повестьны укып чыктым. Гадәттәгечә, бер кич җитте, чөнки Зифа апаның әсәрләрен укый башлагач, аерылып булмый. "Язмышыңа язылганны..." повесте — бүгенге көн, сугыш, яши дә башламаган яшьләрнең аяк-кулсыз калып бәргәләнүе, аналар күз яше турында...

Зифа апаны күптәннән беләм, Чаллыга баргач, фатирында кунак та булырга туры килде. Эчкерсез, бик кунакчыл, рәхәт кеше дип әйтә алам аны. Бу юлы да сөйләшүебез ихлас булды.

**Зифа КАДЫРОВА:**

# "ТӨП ГЕРОЙНЫҢ АЛГА ТАБА ЯШИСЕ БАР..."

## "2021 ЕЛДА ЯЗА БАШЛАГАН БИШ ӘСӘРЕМ БАР"

**— Зифа апа, сигезенче китабыгыз дөнья күрү белән котлыйм. Укучылар тарафыннан яратып кабул ителәчәгенә шигем юк. "Язмышыңа язылганны..." повесте башкаларыннан кайсы ягы белән аерыла, ничек уйлыйсыз?**

— Рәхмәт. Шулай булсын. Беренчедән, шуны әйтәсем килә: һәр китап чыкканнан соң күңелдә җылылык урнаша. Һәм ниндидер бер курку да барлыкка килә: укучы ничек кабул итәр? Ә менә ничек сатылыр дигән уй тумый, чөнки сатыласын беләм. Синең сорауга җавап: бу китабым башкаларыннан актуальлеге белән аерыла. Заманга ияреп барырга, халык белән бергә атларга тырышам.

2021 елда яза башлаган биш әсәрем бар. "Язмышыңа язылганны..." повесте — шуларның берсе. Ул чакта әсәрдә Чечня сугышында булган хәлләрне күтәргән идем, тик ул тәмамланмыйча калды. Аннан махсус хәрби операция башланды. Нәтиҗәдә, әсәремне дәвам итеп, бүгенге тормышка кайтарып калдырдым. Әле махсус хәрби операция тәмамланмады, төп геройның да алга таба яшисе бар. Шулай булгач, повестьның дәвамы булачак. Гомумән, мондый рухтагы әсәрләрем тагын булыр дип уйлыйм. Һәрхәлдә, аларны күңелдән уйлап куйдым инде.

**— Әсәр буенча нинди кайтавазлар булды?**

— Кемдер тынып калды, әллә шунда куркып та киттеләр. Кайберәүләр исә: "Бу бит ирләр темасы", — дип әйтте. Ә бу тема миңа ят түгел. Мәктәпне тәмамлагач, сыйныфташлар Әфган сугышына китте. Шуннан улымнар буынына Чечня сугышы туры килде. 1998 елда улым армиягә китте, шул чагында Чечняга алмасыннар дип төн йокысы качты. Мин генә түгел, балалары армия яшендә булган һәр ана ут йотып яшәде. Шөкер, безнекен алмадылар. Нәрсә әйтергә телим: безнең халык гомер буе сугыштан куркып яшәгән, яшәде.

**— Әсәрнең исемен 2021 елда ук шулай куйган идегезме?**

— Әсәр язылып бетмичә, аңа исем биреп булмый. Интернетта бер бик мәгънәле җырга тап булдым: "Язмышыңа язылганны" дип атала иде ул. Җырның авторы Рәфкать Шаһиев белән элемтәгә кереп, әсәрнең исемен шулай атыйм әле, дип сорадым. Ул риза булды. Җыр текстын китапка да керттем. Бу җырның мәгънәсе минем геройларга бик туры килә кебек.

Чечня сугышы башлангач, бик күпләр акча түлитүли балаларын армиядән алып калды. Ерак барасы түгел, Чаллыда гына да андыйлар күп булды. Нәтиҗәдә ул егетләрнең бүген күбесе барыбер вафат: эчкечелек, наркомания үз эшен эшләде. Гомерең бетсә...

Улымның сыйныфташлары бүген махсус хәрби операциядә. Әле фотоларын җибәргәннәр: икесенә бер аяк. Берсенең ике аягы да юк, икенчесенеке берәү калган. Ә миңа әсәрне укыган кешеләр: "Ялган бит бу. Бер аяк белән сугышка алмыйлар", — диделәр. Алалар, күреп, ишетеп торабыз.

## "ҺАМАН ДА УКУЧЫЛАРДАН ХАТЛАР КИЛӘ"

**— Зифа апа, сезнең әсәрләрдә һәрвакыт гади кеше язмышы. Күп очракта ул тормыш фаҗигасеннән тора. Үзегез әйтүенчә, нигездә, реаль тормыштан алынган хәлләргә нигезләнеп язасыз. Ә менә "Язмышыңа язылганны..." повесте дөнья күргәннән соң, үзләрен танып килгән кешеләр бармы?**




— Әсәрне укыганнан соң, үзләрен танып килүчеләр булгалый. Охшаш язмышлар да күп. Өченче ел Башкортстанга кайткач, бер матур гына гәүдәле ир-ат килеп керде. "Зифа апа, махсус сезне күрергә һәм рәхмәт әйтергә дип килдем. Сезнең әсәрне укыгач, гаиләмне җыеп ала алдым", — диде. Һаман да укучылардан хатлар килә, арада аеруча якын иткәннәре дә бар. Язучы өчен кайтавазлар алу бик мөһим. Ә "Язмышыңа язылганны..." повестен укыгач, үзен танып килгән кешеләр юк әле.

**— Сезнең шактый әсәрләрегез сәхнәләштерелде. "Язмышыңа язылганны..." повестен да сәхнәгә алып менәргә дигән ният юкмы?**

— Күптән түгел Нәсүр Юрушбаев белән таныштым. Ул әсәрне укып чыкканнан соң: "Зифа апа, бу — әзер сценарий. Украинадагы махсус хәрби операция турында татарча кино төшерелгәне юк, акча булса, иң беренче сезнекен эшләр идек", — диде.

Әсәрне сәхнәгә алып менү миннән тормый, театр үзе шулай хәл итсә, рәхим итсеннәр. Әлбәттә, автор буларак моңа сөенәм генә.

**— Зифа апа, китаплар сакларга махсус склад төзегәнсез икән?**

— Әйе, мин бит 10 ар мең тираж белән китап чыгарам. Кибетләрдә бетә бара, илтә торабыз. Уфа, Казан, Сыктывкар... Татарстан, Башкортстан районнарыннан да килеп алалар. Нишләптер "Язмышыңа язылганны..." китабы Казанда авыррак сатыла әле, Уфадан дүртенче тапкыр килеп алып киттеләр инде.

Иң популяр китабым — "Сагынырсың, мин булмам". Аны берничә тапкыр бастырдык, китапның гомуми тиражы 50 меңнән дә артып китте. Без ул әсәрне рус теленә дә тәрҗемә иттек, "Сөмбел" дип атала. Русча китапны да икешәр тапкыр 3 мең тираж белән бастырдык. Гомумән, китапларымның күбесен кабат-кабат бастырабыз, чөнки сатылып бетә.

"Язмышыңа язылганны..." китабын да русчага тәрҗемә итәргә ният бар. Дөресен әйткәндә, хәзер тәрҗемәчеләр дә, текст белән эшли белә торган мөхәррирләр дә юк. Ә мин корректор, мөхәррирсез китап чыгармыйм, моны яшермим дә.

## "АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ БЕР МИССИЯСЕ ИТЕП КАБУЛ ИТӘМ"

**— Тагын бер сорау бирәсе килә: "Язмышыңа язылганны..." повестенда төп герой Данияр дингә килеп кенә үлемнән кала, гаиләсен кире кайтара. Әсәрне укыганда автор Аллаһы Тәгаләгә сыена, аның барлыгына, берлегенә инана дигән уй килә. Бу шулаймы?**

— Шулай. Гомумән, 20 елга якын язучылык эше белән шөгыльләнәм икән, моны Аллаһы Тәгаләнең бер миссиясе итеп кабул итәм. Мин бит гади завод эшчесе. Ә әсәрләремне беренче көннән үк халык шулай яратып кабул итте. Бу бит могҗиза! Табиблар миндә әллә нинди чирләр таба тора, ә мин яшим. Димәк, бу да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, кодрәте. Һәрхәлдә, шулай дип кабул итәм.

Аннары, тагын бер фикер әйтим әле: китабым чыккач, танышым килде: "Әлеге әсәрне муллалар да укырга тиеш, бу бит аларга инструкция", — диде. Чынлап та, төп герой Даниярга иң авыр чагында авыл мулласы ярдәм кулы суза. Сүгеп түгел,

ә үгетләп, күчтәнәчләр биреп... Аның ярдәме белән Данияр яңадан тормышка кайта. Муллалар әнә шундый булырга тиеш, дип уйлыйм.

**— Бүген сезнениләр сөендерә һәм нәрсәләр борчый, аптырашта калдыра, Зифа апа?**

— Җәй буе бакчамда яшим. Яшь барган саен, адәм баласына җир кирәк, дип уйлыйм. Бакчамда әллә ниләр үсмәсә дә, бәләкәй генә уңышка да сөенәм, чәчәкләремне күреп сокланам, алардан илһам алам. Шунда балалар, оныклар килә, алар белән рәхәтләнеп, бөтен дөньяны онытып, канатланып йөрим.

Борчылу дигәннән, бүген кеше тормышның матурлыгын күрми башлады. Ризыкның тәмен белмибез, тегесе ярамый, монысы фәлән. Хәзер адәм баласы тәүлек буе ашый. Хәтта киногa баргач та туктамый ашап утыралар. Гаҗәп инде, гаҗәп.

Ризык дигәннән, мин кеше сыйларга яратам. Әле күптән түгел корбан ашы үткәрдем. Үземә атап корбан чалдык. Беренче көнне якыннар, туганнарны җыйдым. Икенче көнне Чаллы Язучылар берлегеннән килделәр, 21 кеше булдык. Әнә шулай яшәп ятыш... Алга планнар зур, яңа әсәрләр иҗат итәргә дигән ният бар. Аллаһы Тәгалә саулык, бәрәкәтле гомер насыйп итсен. Бөтен кешегә карата да шул теләктә калам.

**P.S. Зифа Кадырованың китапларын маркетплейслардан, китап кибетләреннән сатып алырга мөмкин.**

**Руфия РӘХМӘТУЛЛИНА.**

БЕЗНЕ НИЧЕК АЛДЫЙЛАР?

## АКЧА ДА, МАШИНА ДА ЮК

Казанда ике ир-ат, автомобиль сатып алганда, мошенниклар тозагына эләккән. 58 яшьлек ир-ат бушлай рекламалар сайтында арзанрак бәягә чит ил автомобиле сатылу турында игълан күргән. Сатучы таможня акчасын түләү өчен акчаны алдан күчерүен сораган. Ир-ат ышанып, аңа 5 млн. сумга якын акча күчергән, әмма автомобильле була алмаган. Мошенниклар, төрле сылтаулар белән, аннан акча таләп итүне дәвам иткән. Икенче казанлыны да шулай алдаганнар, ул 2,5 млн. сумнан артык акчасын югалткан.

Әлеге очраклар буенча җинаять эшләре ачылган, тикшерү бара.





**Кайбер районнарда авыл халкы тынычлап кош-корт асрый алмыйбыз дип зарлана. Кама Тамагы районы Чаллы авылында бернечә хуҗалыктагы тавыкларга төлке һөҗүм иткән.**

**— Төлкенең элек тә килгәне бар иде авылга. Былтыр күренмәде, тыныч булды. Быел менә тагын кош-кортны тота башлады. Аеруча авыл читендә яшәгән кешеләр зыян күрә. Төлке яр кырыенда, бакча башында йөргән тавыкларны аулый. Үзебезнең дә өч тавыгыбызны алырга өлгерде, берсен коткарып калдык. Беркөнне әтәчне куып йөргән. Әле менә балалар читлектән капкын әмәлләп куйдылар. Әләксә... Тавык-чебеш асрарга да куркытып тора, — ди Тәскирә Мозаффарова.**

# "ТЫНЫЧЛАП КОШ-КОРТ ҮСТЕРЕП БУЛМЫЙ"

Буа районы Түбән Нaратбаш авылы халкы да борчуда. Ниндидер җәнлек аларның тавык-үрдәкләренә һөҗүм итә.

— Сасы көзәнгә дә охшаган үзе, алай дисәң, җир өстеннән үткән газ торбалары буйлап чабып киләләр. Күрше авыллар да зыян күрде ул җәнлектән. Кайбер кешенең 40-50 ләп тавыгын буганнар, — ди Түбән Нaратбаш авылыннан Рәзинә Хәсәнова.

Кайберәүләр бу җәнлекне куркытыр өчен радио кабызып куялар икән.

— Көн-төн радио эшләтәбез хәзер. Кайбер кеше безне кич бәйрәм итә дип уйлый. Ә без шулай тавыкларны саклыйбыз. Радио сөйләп торгач, җәнлек курка, килми, — ди Буа районының Зур Кырлаңгы авылы халкы.

— Буш калай савытларны казыкка кагып куючылар да бар. Савыт җилдә селкенеп тавыш чыгара, бу да сасы көзәнне куркытырга ярдәм итә, — ди Рәзинә апа. Үзләре капка төбенә эт бәйләп куйганнар. — Шуннан бирле тыныч әле, җәнлекнең кергәне юк, шөкер.

Башкортстанның Бакалы районы Яңа Илек авылында билгесез җанвар бер хуҗалыкта 70 тавыкны буып чыгып киткән. Авыл халкы төлке эшедер дип уйлый. Белгечләрне дә чакырткаnnar. Авыл янында төлке балалаган, дигәннәр. Әмма тавыклар күпләп үлү сәбәбе бер төлке аркасында гына түгел, бу чәшке, сасы көзән дә булырга мөмкин, дип кисәткәннәр.

— Быел тычкан, әрлән, көзән кебек җәнлекләр күбәйде. Азык күп, көннәр җылы, рәхәтләнеп яшиләр, — ди зоолог, биология фәннәре докторы Илгизәр Рәхимов. — Сасы көзән бер урынга ояласа, үзе янындагы бөтен нәрсәне үтереп бетерми туктамый инде ул. Аннан җайлы гына котылып та булмый. Шуңа да хуҗалыкларга саклык чаралaрын күрергә, көзән керә алырлык бөтен тишекләрне томалап чыгарга кирәк. Сасы көзән тавыкны махсус ауламый анысы. Тик бер җирдә җыелып торган кош-корт аның өчен табыш. Ул аларны ашамый да, буа да өеп кенә куя. Көзәннәрне атарга ярамый. Аларны кул белән тотып булмый. Махсус капкын куллансаң гына. Төлкеләргә килгәндә, алары кешедән, эттән курка. Шуңа да каралты-курага бик якын килми. Ә менә өй тирәсендә йөргән тавык-чебешкә һөҗүм итәргә мөмкиннәр. Ау сезоны вакытында төлкене атарга ярый. Капкынга эләксә, җәрәхәтләнгән булса, кире урманга җибәрүдән мәгънә юк, үзеңә бүрек тегеп кисәң генә. Агуларга киңәш ителми, чөнки хайваннар ул агуны таратырга мөмкиннәр. Урман-кырларда агу калдыру бер хәл, каралты-кура тирәсенә куйсаң, үз тавыгың да шуны ашап агуланырга мөмкин бит. Иң яхшысы — авылда төлкеләр күбәйгән һәм зарар китерәләр икән, экологларга, белгечләргә хәбәр итәргә кирәк. Беркөнне Арча юлыннан узганда, карыйм, кырда челән басып тора. Ул, гадәттә, сулыкларда яши. Печән чапкан җирдә тычкан оялары күренеп калган. Челән тычкан чыкканны көтеп тора, чыгуга томшыгы белән эләктереп ала. Кешедән дә курыкмый. Хайваннар дөньясында да үзгәрешләр булып тора. Алар хәзер ялкауландымы шунда. Әзер, якындагы ризыкны гына ашарга торалар. Җим эзләп мәшәкатьләнмиләр. Җайлы юлны сайлыйлар.

**Эльвира МОЗАФФАРОВА.**



## АДРЕСЛАР ЧУАЛГАН

**Илдә бер үк атамадагы 67 шәһәр бар — барлыгы 31 кабатлана торган исем.**

— Россиядә 1 250 дән артык шәһәр исәпләнә, шуларның 67 сенең исемнәре кабатлана (31 исем), — дип хәбәр итә Роскадастр. Иң еш очрый торган атамалар: Александровск, Кировск, Красноармейск, Приморск һәм Советск. Әле бертөрле, охшаш атамалы авылларны саный башласаң... Бу буталчыклар китереп чыгара. Бер генә мисал — 2018 елда Футбол буенча дөнья чемпионаты барганда Аргентина җанатарлары Түбән Новгород урынына Бөек Новгородка киткән һәм яраткан командаларының уенын күрми калган иде.

## КҮГӘРЧЕННӘР НИК ҮЛӘ?

**Казанда Урицкий паркында, шәһәр үзәге Бауман урамында, сулыклар тирәсендә күпләп үлгән күгәрченнәргә юлыкканнар.**



— Җәен күгәрченнәрдә Ньюкасл авыруы (ул "вертячка" дип атала) кебек чирләр тарала, алардан кошларның яртысы кырылып бетәргә мөмкин. Кошларның агулану ихтималы да бар. Гигиена таләпләрен үтәгәндә, кеше сәламәтлегенә куркыныч янамый. Үлгән кошларны тотмаска, кулларны ешрак юарга кирәк, — дигән Россия кошларны саклау берлеге хезмәткәре Елена Чернова "Татар-информ"га.